Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Средняя общеобразовательная школа №8 г.Нурлат Республики Татарстан»

| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждено» |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО МБОУ «СОШ № 8 » | Заместитель руководителя по УР МБОУ «СОШ № 8» | Директор МБОУ «СОШ № 8» |
| ______/____________ Ф.И.О | ______/____________ Ф.И.О. | ______/____________ Ф.И.О. |
| Протокол № 1 от «27» 08 2018г. | «28» 08 2018 г. | Приказ № 253 от «29» 08 2018 г. |

Рабочая программа
учебного предмета «Родной (татарский) язык»
для русскоязычных учащихся 7класса
Ахметовой Гузалии Исламовны,
учителя родного языка и литературы,
первой квалификационной категории.

Принята на заседании
педагогического совета школы
протокол № 1 от 29 августа 2018 г.

2018-2019 учебный год

**Укыту фәнен үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Предмет нәтиҗәләре:**

- татар телендә телдән яки язмача аралашу күнекмәләрен үзләштерү;
- коммуникатив бурычлар куя һәм аларны хәл итә белү; сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- “Татар теле” фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.

**Сөйләм.**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-сөйләм этикеты нормаларын саклап диалогларда катнашырга;

-рәсем буенча хикәя төзергә;персонажларны тасвирларга;

-үзе, гаиләсе, дуслары турында сөйләргә;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белергә;

- өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белергә;

-геройларга характеристика бирергә;

- укыган хикәяләрнең эчтәлеген кыскача сөйли белергә;

**Аудирование**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- аралашу барышында чит сөйләмне ишетеп аңлау;

-зур булмаган текстларны аудиоязмада тыңлап аңларга;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-аудиотекстларның эчтәлеген аңларга;

- текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңларга.

**Уку**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-программада тәкъдим ителгән әдәби әсәрләрне, әсәрләрдән өзекләрне, автор текстларын, орфоэпик нормаларны саклап, сәнгатьле укырга;

- зур булмаган текстларны үзлектән аңлап укырга һәм кирәкле мәгълүматны табарга;

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-контекст буенча таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен аңларга;

**Язу**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-тексттан сүзләрне, сүзтезмәләрне күчереп язарга;

-котлау открыткалары язарга;

-дустына кыска күләмле хат язарга.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-текст сорауларына язмача җавап бирергә;

-конкрет бер тема буенча хикәя төзеп язарга;

-анкета тутырырга;

Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре

Графика,каллиграфия,орфография

**Укучы өйрәнәчәк:**

-татар алфавитын белергә, хәрефләрне дөрес язарга;

-бирелгән текстны күчереп язарга;

-сүзләргә төшеп калган хәрефләрне куеп язарга;

-язу һәм укуның төп кагыйдәләрен, программада бирелгән сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын белергә;

-хәрефләрне авазлардан аера белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

-сүзләргә фонетик анализ ясый белергә;
-орфографик, тәрҗемә,аңлатмалы сүзлекләр белән эшли белергә;
Сөйләмнең фонетик ягы
**Укучы өйрәнәчәк:**
-телдән сөйләм яисә кычкырып уку барышында, татар теленә хас авазларның әйтелеш нормаларын сакларга;
-сүз, фраза басымын дөрес куеп укырга;
-җөмләләрнең ритмик-интонацион үзенчәлекләренә карап, төрләрен (хикәя, боеру, тойгылы) аера белергә;
**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
-бәйләнешле сөйләм төзи белергә;
-сөйләмдә интонаця куллана белергә;
-сүзләрне транскрипциядә укырга;
Сөйләмнең лексик ягы
**Укучы өйрәнәчәк:**
- телдән һәм язма сәйләмдә программага кертелгән лексик берәмлекләрне дөрес әйтергә һәм кулланырга;
- сөйләмдә коммуникатив максатка туры килгән гади тотрыклы гыйбарәләр, клишеләр кулланырга;
Укучы әйрәнергә мәмкинлек алачак:
-сүз ясалышының төрле элементларын танырга;
**Сөйләмнең грамматик ягы**
**Укучы өйрәнәчәк:**
- сөйләм нормаларын саклап, хикәя, сорау, боеру җөмләләр, раслау һәм инкарь җөмләләр төзергә;
-өйрәнгән сүз төркемнәрен тексттан табарга, аларна сөйләмдә кулланырга;
**Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:**
-теркәгечле, теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне танырга;
-сөйләмдә бер составлы җөмләләрне кулланырга;
-зат, сорау, күрсәтү, билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыкларын сөйләмдә танырга, дөрес кулланырга;
- сыйфат дәрәҗәләрен аера алырга, чагыштырга, артыклык дәрәҗәләренә куя, сөйләмдә куллана белергә;
-хикәя фигыльнең заман формаларын аерырга;
-бәйлекләрне, бәйлек сүзләрне, кереш сүзләрне, теркәгечләрне, кисәкчәләрне сөйләмдә урынлы кулланырга.
-татар теленең фонетик, лексик, грамматик катламнарын һәм аларның берәмлекләрен гамәли куллана белү;
-сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештыра белү;
-актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне сөйләмдә куллана белү;
-тыңланган яки укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, кирәкле мәгълүматны җиткерә алу;
-тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан эзлекле монологик һәм диалогик сөйләм төзи алу;
- татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итә алу.
**Метапредмет нәтиҗәләре**
Танып белү универсаль уку гамәлләре:
- логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү төрендәге проблеманы билгеләү, аны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне табу;
- төп мәгълүматны аерып алу, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
-тиешле мәгълүматны табу әчен , энциклопедия, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мәстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләренә ия булу;
- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычлар билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый һәм, кирәк булганда, төзәтмәләр кертә белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- әңгәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңлый һәм аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәшең белән аралашу калыбн төзү;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
- аралаша белү сәләтен үстерү;
- парлап һәм төркемдә эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эшчәнлектә катнашу.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караштa булу һәм аны яхшы өйрәнү теләгенә ия булу;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү;
- гаилә, туган ил, туган җир, мәрхәмәтлелек төшенчәләрен аңлап кабул итү; укучыда башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык, кеше кадерен белү кебек хисләр формалашу.

**Укыту предметының эчтәлеге**

***Белем һәм тормыш (32 сәгать)***

Уку. Яхшы уку кагыйдәләре.Уку-язу әсбаплары. Китаплар дөньясы.
Китапханәдә.

**Без бергә ял итәбез. ( 20 сәг)**

Буш вакыт. Яраткан шөгыльләр. Виртуаль аралашуның төрле ысуллары. Ял итү урыннары (кино, театр, парк, кафе һ.б.). Сәяхәт итү.

**Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә (15 сәг)**

Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәтләре. Рөхсәт сорау.Өлкәннәрне хөрмәтләү.Бәйрәм белән котлау. Кунакта. Яраткан ризыклар. Табын артында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Туган көн. Милли бәйрәмнәр. Милли ризыклар.

**Татарстан Республикасы. (10 сәг)**

Татарстанның географик урыны, климаты, халкы. Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. Татарстанда яшәүче милләтләр. Казан – Татарстанның башкаласы. Татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате. Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында.

**Лингвистик белем һәм күнекмәләр.** Программага кертелгән аралашуның актив лексикасы. Гади тотрыклы төзелмәләр. Татар һәм рус телләре өчен гомуми лексика. Татар сөйләм этикетлары - клише (мөрәҗәгать, үтенеч белдерү, тәкъдим, тәкъдимне кире кагу, гафу үтенү, теләк белдерү, ризалашу, ризалашмау, гаҗәпләнү, ризасызлык белдерү, хөрмәт һәм рәхмәт белдерү).

**Сөйләмнең грамматик ягы.** Мөстәкыйль сүз төркемнәре.

Исем сүз төркеме. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.

Сыйфат сүз төркеме. Сыйфатларның гади, чагыштыру, артыклык дәрәҗәләре.

Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре: саф рәвешләр (тиз, акрын, җәяү), күләм-чама рәвешләре (күп, аз, бераз), охшату-чагыштыру рәвешләре (татарча, русча, зурларча), вакыт рәвешләре (иртәгә, бүген, җәен, кичен), урын рәвешләре (анда, еракта, уңга, сулга).

Боерык фигыль. 2, 3 зат берлек һәм күплек сандагы боерык фигыльләр. Боерык фигыльләрдә басым үзенчәлеге.

Теләк фигыль. Теләк фигыльнең 1 зат берлек һәм күплек сан формалары.

Исем фигыль.

Сыйфат фигыль. Сыйфат фигыльнең хәзерге, үткән заман формалары: - учы/-үче; -а/-ә, -ый/-и торган; -ган/-гән, -кан/-кән

Хәл фигыль. Хәл фигыльнең –ып/-еп/-п; -гач/-гәч, -кач/-кәч; -ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче формалары.

Бәйләгеч сүз төркемнәре.

Теркәгечләр. Җыючы теркәгечләр: һәм, да-дә, та-тә; каршы куючы теркәгечләр: ләкин, тик, әмма, ә; ияртүче теркәгечләр: чөнки, әгәр.

Кисәкчәләр. –мы/-ме, бик, түгел, тагын, әле, -чы/-че, гына/генә, кына/кенә кисәкчәләре, аларның язылышы.

Синтаксис. Әйтелү максаты буенча җөмлә тѳрләре: хикәя, сорау, тойгылы. Җөмләдә сүзләр тәртибе. Гади фигыль хәбәрле (Мин татарча беләм), исем хәбәрле (Безнең гаиләбез тату), тезмә фигыль хәбәрле (Мин укырга яратам) гади җөмләләр.

**Тематик планлаштыру**

| № | Б. с. | Тема | Сәг.саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Фактик |
| | 1 бүлек. *“ Белем һәм тормыш” (32 сәгать)* | | | | |
| 1 | 1 | Белем бәйрәме котлы булсын. | 1 | 04.09 | |
| 2 | 2 | Мәктәптә белем көне. | 1 | 06.09 | |
| 3 | 3 | “Минем җәйге ялым” темасына караган лексик-грамматик материал. | 1 | 11.09 | |
| 4 | 4 | “Минем җәйге ялым” темасына караган лексик-граматик материал. | 1 | 15.09 | |
| 5 | 5 | Сүз төркемнәре . Исем | 1 | 18.09 | |
| 6 | 6 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | 22.09 | |
| 7 | 7 | Сыйфат | 1 | 25.09 | |
| 8 | 8 | Сыйфат дәрәҗәләре | 1 | 29.09 | |
| 9 | 9 | Фигыль | 1 | 02.10 | |
| 10 | 10 | Фигыль төркемчәләре | 1 | 06.10 | |
| 11 | 11 | “Мәктәптә беренче көн” текстындагы лексик-грамматик материал | 1 | 09.10 | |
| 12 | 12 | “Минем мәктәп режимым”темасына сөйләшү | 1 | 13.10 | |
| 13 | 13 | “Буш вакыт” тексты буенча эш | 1 | 16.10 | |
| 14 | 14 | Татарстан музейлары | 1 | 20.10 | |
| 15 | 15 | “Безнең музейларыбыз” | 1 | 23.10 | |
| 16 | 16 | Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 | 27.10 | |
| 17 | 17 | “Без бергә дәрес әзерлибез”. | 1 | 6.11 | |
| 18 | 18 | Без бергә китапханәгә йөрибез” | 1 | 10.11 | |
| 19- | 19 | Рәвеш төркемчәләре. | 1 | 13.11 | |
| 20 | 20 | Рәвеш төркемчәләре. | 1 | 13.11 | |
| 21 | 20 | “Без китаплар укыйбыз” | 1 | 17.11 | |
| 22 | 21 | “Белем һәм тормыш” темасы буенча контроль эш№1. | 1 | 20.11 | |
| 23 | 22 | Хаталар өстендә эш.<br>Сәбәп белдерү формасы. | 1 | 24.11 | |
| 24 | 23 | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. | 1 | 27.11 | |
| 25 | 24 | “Көндәлек – документ, көндәлек – синең көзгең” темасы буенча лексик-грамматик материал. | 1 | 1.12 | |
| 25 | 25 | “Көндәлек – документ, көндәлек – синең көзгең” темасы буенча лексик-грамматик материал. | 1 | 4.12 | |
| | | **2 бүлек. Без бергә ял итәбез. ( 20 сәг)** | | | |
| 26 | 1 | “Көндәлек – документ, көндәлек – синең көзгең” темасы буенча тест | 1 | 8.12 | |
| 27 | 2 | Хаталар өстендә эш. “Безнең көндәлекләребез” | 1 | 11.12 | |
| 28 | 3 | “Яхшы уку кагыйдәләре” темасы буенча лексик-грамматик материал | 1 | 15.12 | |
| 29 | 4 | Инфинитив+ кирәк” төзелмәсе | 1 | 18.12 | |
| 30 | 5 | Белем һәм тормышка караган лексик-грамматик материалны гомумиләштереп кабатлау | 1 | 22.12 | |
| 31 | 6 | Контроль эш №2 “Без бергэ ял итэбез” темасы буенча. | 1 | 25.12 | |
| 32 | 7 | Сыйфат фигыльнең заман формалары. | 1 | 12.01 | |
| 33- | 8 | «Тәрбияле булу заманчамы? » | 1 | 19.01 | |
| 34 | 9 | «Тәрбияле булу заманчамы? » | 1 | 21.01 | |
| 35 | 10 | Җөмләнең баш кисәкләре. | 1 | 22.01 | |
| 36-37 | 11 | “Буш вакыт” темасына караган лексик-грамматик материал”. | 2 | 26.01 | |
| 38 | 12 | . Изложение №2 “Кинога барганда” | 1 | 29.01 | |
| 39 | 13 | Хаталар өстендә эш.Ия белән хәбәр арасындагы сызык | 1 | 2.02 | |
| 40 | 14 | Буш вакыт – ул нинди вакыт? | 1 | 5.02 | |
| 41 | 15 | “Минем буш вакытым булса?” | 1 | 9.02 | |

**ПРИЛОЖЕНИЯ**

**Лист корректировки учебной программы**

| № урока | Тема урока | Причина изменения в программе | Способ корректировки |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

**7 нче сыйныф өчен “Белем һәм тормыш” темасы буенча контроль эш №1 .**

**I вариант**

А1. Дөрестәрҗемәнетабыгыз. ***Чәчәкләр үстерергә ярата.***

а) Любит дарить цветы;

б) Любит выращивать цветы;

в) Любит ухаживать за цветами.

А2. Дөрес сүзне куегыз.

***Дәрестә ... сөйләшергә ярамый.***

а) дөрес;

б) кычкырып;

в) пышылдап.

А3. Хәл фигыль кушымчалары.

а) -гач, -п, -лар, -ны;

б) -п, -а/-а, -гач, -канчы;

в) -еп, -п, -ган, -гәнче.

А4.Хәзерге заман хикәя фигыль кушымчалары.

а) -ларга, -ый, -а, -ды;

б) -а, -ә, -ый, -и;
в) -нчы, -ган, -и, -а.
А5. Билгеле үткән заман хикәя фигыль кушымчалары.
а) -а, -ган,- и, -ды;
б) -нче, -лар, -ләр,-н;
в) -ды, -де, -ты, -те.
А6. Антоним парын табыгыз.
***белемле***
а) акыллы; б) надан; в) усал.
А7. Сүзләрдән җөмлә төзегез.
***Белми, татар, Коля, шуңа курә, ялкау, телен, бик.***
а)6,7,5,4,1,3,2;
б)3,7,5,4,2,6,1;
в) 7, 4,6,3,1, 2, 5.
81. Посоветуй другу:
- бережно обращаться с книгой;
- не писать с ошибками;
- быть вежливым.
82. Как скажете о том, что:
- Марат вышел к доске;
- вы задание не поняли.
83. Составьте диалог по схеме:
- Совет;
- Вопрос;
- Убеждение;
- Согласие.
С1. Напишите небольшой рассказ на тему: ***"Минем яраткан дәресем".***

**7 нче сыйныфөчен контроль эш. “Белем һәм тормыш”. II вариант**

А1. Иянеңсораулары.
а) нинди? кем?
б) кемне? кайсы?
в) кем? нәрсә?
А2. Билгесез үткән заман хикәя фигыль кушымчалары.
а) -ачак, -ячак, -әчәк, -ячәк;
б) - ган, -гән,-кан,-кән;
в) - а, -ә, -ый, -и.
А3. Рәвешләр рәтен табыгыз:
а) ак, матур, тиз;
б) тиз, әкрен, кичә;
в) кичә, уйнап, кызыл.
А4. Боерык фигыльнең сораулары.
а) нишләргә? нишләмәскә?
б) нишләгән? нтшләмәгән?
в) нишлә? нишләмә?
А5. Антоним парын табыгыз.
***файдалы***
а) кирәкле; б) зарарлы; в) тәртипле.
А6. Дөрес сүзне куегыз
***Гыйззатуллин училищены... качты.***
а) уйнап; б) ташлап; в) йөгереп.

A7. Сүзләрдән җөмлә төзегез.

***Малай, чөнки, тырыш, укый, Миша, яхшы, бик.***

а)6,7,5,4,1,3,2;

б)3,7,5,4,2,6,1;

в) 5, 6,4,2,7, 3, 1.

81. Посоветуй другу:

- внимательно слушать учителя;
- быстрее думать;
- быть скромным.

82. Как скажете о том, что:

- вы идете на вечер Разиля Валеева;
- скромность украшает человека.

83. Составьте диалог по схеме:

- Совет;
- Вопрос;
- Убеждение;
- Согласие.

С1. Напишите небольшой рассказ на тему: ***"Минем яраткан дәресем".***

**7 нче сыйныф өчен ““Без бергә ял итәбез” темасы буенча контроль эш №2 .**

**1 нче вариант**

1. ***Сүзләрнең тәрҗемәсен языгыз:***

Файдалы - ...

Буш вакыт - ...

Начар гадәт –

Риза түгел - ...

минемчә - ...

1. ***Җөмләләрне дәвам итегез:***

Минем буш вакытым аз, чөнки...

Буш вакытымны файдалы үткәрәм, ләкин ...

Тәмәке тарту – начар гадәт, чөнки ...

1. ***Выразите желание вместе с другом (подругой):***

- пойти на дискотеку

- сходить в библиотеку

***4. Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез:***

- ...?

- Әйе, бүген буш вакытым бар.

- ...?

- Мин синең белән дискотекага барырга риза.

***5. Спросите у друга:***

- какое у него любимое занятие

- играет ли он в шахматы

- слушает ли он музыку

- есть ли у него свободное время

- любит ли он шоколад

**7 нче сыйныф**

**7 нче сыйныф өчен “Без бергә ял итәбез”темасы буенча контроль эш №2 .**

**2 нче вариант**

1. ***Сүзләрнең тәрҗемәсен языгыз:***

Яраткан шөгыль - ...

Буш вакытым- ...

Тәмәке тарту –

Риза - ...

Тулысынча - ...

1. ***Җөмләләрне дәвам итегез:***

Минем буш вакытым күп, шуңа күрә...

Минем буш вакытым булса, ...

Ул буш вакытында спорт түгәрәгенә йөри, шуңа күрә ...

1. ***Выразите желание вместе с другом (подругой):***

- пойти в кино

- пойти в школу

***4. Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез:***

- Олег, әйдә чана шуарга барабыз.

- ...?

- Сәгать алтыда.

- ...?

- Әйе, Айдар белән Гена да бара.

***5. Спросите у друга:***

- какое у него любимое занятие

- играет ли он в шашки

- читает ли он книги

- много ли у него свободного времени

- ходит ли он в бассейн

**7 нче сыйныф өчен " Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә"темасы буенча контроль эш №3 .**
**1 вариант**

1. **Сообщи о том:**
   - что тебе хочется пить; (эч)
   - что тебе хочется спать; (йокла)
   - узнай у одноклассника, куда он хочет пойти?
2. **Выбери глаголы, в которых в прошедшем времени прибавляются окончания -ды/-де**
   Сакла, пычрат, агула, яса, кайгырт, үс, чыгар, җый, көрәш.
3. ***3.*** **Выпишите слова, отвечающие на вопрос** ***нишләгән?***
   Пычрата, саклаган, агулаган, кайгырта, тоткан, үсә, чыккан, үткән, җыя, ага, җибәрә, ясалган.
4. ***4.*** **Напишите глаголы, добавляя к каждому из них подходящие местоимения:** ***мин, син, ул, сез.***

Көрәшәм, пычратасыз, барабыз, җыясыз, сакламыйсың, кулланмыйм, ачуланмыйсың, ял итәсез, тели.

5. **Образуйте тремя способами глаголы желательного наклонения.**

Тырыш, ял ит, кил.

**7 нче сыйныф өчен " Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә"темасы буенча контроль эш №3 .**

**2 вариант**

1. **Төшеп калган хәрефләрне куеп яз.**

Г...ди, кагыйд...ләр, кайб...р, өлк...н, игътиб...р, к...н...г...ть, г...еп.

2. **Тәрҗемә ит.**

1).танышу кагыйдәләре- юл йөрү кагыйдәләре-

Әдәп кагыйдәләре- исәнләшү кагыйдәләре-

3. **Җөмләләрне тәрҗемә ит.**

1).Он часто обижается. По-моему, это плохая привычка.

2).Мы с друзьями встречаемся часто и весело проводим время.

3). С воспитанными людьми легко общаться, потому что они умеют внимательно слушать.

4). Умение интересно рассказывать –это тоже талант.

**4. Посоветуй другу:**

- при разговоре держать себя свободно;
- при беседе не перебивать собеседника;

-внимательно слушать собеседника.

**5. Предложи другу:**

- вместе готовить уроки;
- вместе сходить в лес;
- вместе поработать на даче.

**7 сыйныф өчен арадаш аттестация эше.**

**1.Тәрҗемә итегез.**

Виляет хвостом –
Крутится возле хозяина
Радостно прыгает-
Глаза горят
Радостно лает
Ждет хозяина –

**2. Тәрҗемә итегез.**

Тәпиен биреп, исәнләшә –
Мәктәптән каршы ала–
Шатланып, койрыгын болгый–
Бияләйне салдыра. –
Сумканы алып бара –
Туп белән уйнарга ярата –
Арт аягында басып тора-

**3. Как скажете, что:**

- Ваша собака умная;
- Собака друга умеет здороваться
- Вы часто гуляете с собакой
- Собака Рустама длинноухая
- Друг очень любит свою собаку

**Спроси у одноклассника :**

- Есть ли у него собака?
- Какая кличка у собаки?
- Какая собака?

**4. Хикәя төзегез “Татарстан –минем республикам”.**
**5. Эшчән, саран, һәрвакыт, ел фасылы. Составить предложения.**

**Тема: Әти-әниләргә булышабыз**

**1. Тәрҗемә итегез**.

ярдәм итәбез - юабыз –

сөртәбез - булышабыз –

**2. Хикәяне күчереп языгыз. Баш килештәге исемнәрнең астына сызыгыз.**

Малай белән кыз мәктәптән кайталар. Алда бер әби бара. Урамда бозлавык. Әби кинәт егылды. Малай портфелен кызга бирде һәм әбигә торырга булышты.

**3. Бирелгән сорауларга җавап языгыз.**

Нишли? булыша җыештыра тузан сөртә

Нишләде? .......... ............... ..............

Нишләгән? .......... ............... ..............

Нишләргә? .......... .............. ...............

**4. Дөрес тәрҗемәне табыгыз.**

идән юа

1) вытирает пол

2) поливает цветы

3) моет пол

булышабыз

1) поливаем

2) помогаем

3) работаем

вытираю

1) сибәм

2) булышам

3) сөртәм

җыештыра

1) поливает

2) убирает

3) моет

**5.Зат-сан белән төрләнешне дәвам итегез.**

Мин ярдәм итәм. Без .......... .

Син ................. . Сез ......... .

Ул .................. .                                        Алар ........ .

**Контроль изложение. Кинога барганда**

Көн матур, кояшлы иде. Агачлардан тәмле ис килә. Бал кортлары бал җыя иде. Әнисе Шамилгә кибеткә барырга кушты. Шамил кибеткә китте. Юлда сыйныфташы Салихны очратты. Ул кинога бара иде. Шамилнең дә кинога барасы килә. Әнисеннән рөхсәт сорады. Шамил кинога китте. Кинога барганда, яңгыр ява башлады. Шамил түбәле капка янына туктады. Аның янына яланаяклы бер кыз килеп басты. Кинәт кыз кычкырып җибәрде: “Акчам юк! Акчам агып китте! Күрше апа авырый. Аңа дару адып кайтырга кирәк. Ул мине көтә”. Шамил бер акчага, бер кызга карады. Кинога да барасы килә, кыз да кызганыч...